# КАРАР
## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Алга торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 29 ноябре,** **Алга авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 29 ноябрендә Алга торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Алга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- Полевая урамы буенча юл аша урнаштыру өчен 500см диаметрлы торба сатып алу һәм урнаштыру;;
- зиратта каты көнкүреш калдыклары өчен өч контейнер сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 36 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 23 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 23 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Алга торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.
2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Алга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара

салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
- Полевая урамы буенча юл аша урнаштыру өчен 500см диаметрлы торба сатып алу һәм урнаштыру;;
- зиратта каты көнкүреш калдыклары өчен өч контейнер сатып алу,кабул ителгән

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Үзәк авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үзәк авыл җирлеге Башлыгы: В. Н. Котников